СОВЕТ МАМАДЫШ-АКИЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Мамадыш-Әкил ав.

**2024 елның 03 июнь** **№168**

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип танунын өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы Карар кабул итте:

1. 1 нче кушымта нигезендә җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танунын өстәмә нигезләрен билгеләргә.
2. Мамадыш-Әкила авыл җирлеге Советының 2023 елның 01 июнендәге 126 номерлы «җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип танунын өстәмә нигезләрен билгеләү турында»карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә һәм Мамадыш-Әкил авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин урамы, 50 йорт (администрация бинасы), Татар Танае авылы, Үзәк урамы, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы), Паново авылы, Үзәк урамы, 20а йорт (авыл клубы бинасы).

Мамадыш-Әкил авыл Җирлек башлыгы,

Совет рәисе: Ф.Ф.Мирхәтуллин

1 нче кушымта

Мамадыш-Әкил авыл жирлеге Советы карарына

2024 елның 03 июнендәге 168 номерлы

Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләтү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч өметсез дип танылa:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) 1 пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) 1 пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда.

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) 1 пунктның 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булуы турында белешмәсе.